**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр,17йорт, Актаныш ав, 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ____________ ПР-245 14.11.2024 КАРАР №_____

**«2025 елга «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында»**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2013 елның 30 декабрендәге 1096 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2025 елга түбәндәгеләрне расларга:

«Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар;

2. «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасына белем бирү оешмаларының әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнары нигезендә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Д.М.Әнвәровага йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов

Расланган
«Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары
«___» ________ 2024 №____ белән

**«Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль дислокация | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сумнарда |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 119559 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | авыл җирлеге | 181658 |